ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.08.2020 ел Баулы шәһәре №157

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 29 мартындагы 86 номерлы карары (2019 елның 26 сентябрендәге 275 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2020 елның 07 июлендәге 01-51/4582 номерлы хатына таянып, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. «Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау һәм аларны бирү өчен җаваплы администраторларны билгеләү турында» Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 29 мартындагы 86 номерлы карары белән расланган Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә (2019 елның 26 сентябрендәге 275 номерлы үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

«Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә эш» бүлегендә 26нчы пунктны төшереп калдырырга;

27, 28, 29, 30, 31, 32, 33, 34, 35, 36, 37нче пунктларны 26, 27, 28, 29, 30, 31, 32, 33, 34, 35, 36нчы пунктлар дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров